СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2019 Баулы шәһәре № 213

Муниципаль контроль төрләре
исемлеген алып бару тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль районында муниципаль контроль төрләре һәм аларны Баулы муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен кушымта нигезендә расларга.

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына муниципаль контроль төрләре исемлеген расларга һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы
Советының 2019 елның 20 маенда
кабул ителгән 213 санлы
карарына кушымта

Баулы муниципаль районында муниципаль контроль төрләре
һәм аларны Баулы муниципаль районы территориясендә
гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары
исемлеген алып бару
Тәртибе

1. Баулы муниципаль районында муниципаль контроль төрләре һәм аларны Баулы муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибе (Алга таба – Тәртип), «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматның ачыклыгын тәэмин итү максатларында эшләнгән һәм Баулы муниципаль районында муниципаль контроль төрләре һәм аларны Баулы муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген формалаштыру һәм алып бару процедурасын билгели (алга таба - Исемлек).

2. Исемлек Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының хокукый акты белән билгеләнгән вәкаләтле структур бүлекчәсе ( алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан, әлеге Тәртипкә кушымтадагы форма буенча төзелә һәм алып барыла.

3. Исемлеккә түбәндәге мәгълүмат кертелә:

1) Баулы муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре исеме;

2) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары исеме, аларның урнашу урыны, телефон;

3) муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль норматив хокукый актының атамасы һәм реквизитлары;

4) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында җирле үзидарә органы муниципаль норматив хокукый актының атамасы һәм реквизитлары.

4. Контроль төрләре исемлегенә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелә:

1) муниципаль контрольнең яңа төрен кертү яки муниципаль контроль төрен төшереп калдыру зарур булганда;

2) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаучы норматив хокукый актлар реквизитларына төгәллек кертү максатларында;

3) муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы исемен үзгәртү белән бәйле рәвештә.

5. Исемлек Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

___________________

Баулы муниципаль районында муниципаль
контроль төрләре һәм аларны Баулы муниципаль
районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле
җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару
тәртибенә кушымта

## Баулы муниципаль районында муниципаль контроль төрләре һәм аларны Баулы муниципаль районы территориясендә тормышка ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге

| № п/п | Муниципаль контроль төре атамасы | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр бирелгән Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органы атамасы (урнашу урыны, телефоны) | Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органының муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрен билгели торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актының, Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль норматив хокукый актының атамасы һәм реквизитлары | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында җирле үзидарә органы муниципаль норматив хокукый актының атамасы һәм реквизитлары |
| --- | --- | --- | --- | --- |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |